**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның «12» июленнән № 35-282

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының2022 елның 29 декабрендәге 30-239 номерлы карары (алга таба-Карар) белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисенә, муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2.1 пунктының бишенче абзацында «башка түләүләр түләнергә мөмкин» дигән сүзләрне «башка түләүләр түләнә» дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.2. Карарның 3.3 пунктында «, җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан түбәндәге күләмнәрдән арттырмыйча билгеләнә торган:» сүзләрен «түбәндәге күләмнәрдән арттырмыйча билгеләнә:» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Карарның 3.8 пунктында «матди ярдәм түләнергә мөмкин» дигән сүзләрне «матди ярдәм түләнә » дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.4. Карарның 2 нче кушымтасындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәр үлгән очракта, аның гаиләсенә элек биләгән вазыйфасы буенча айлык акчалата түләү күләмендә бер тапкыр түләнә торган пособие түләнә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа

Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов